| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2019 г. Иске Чүпрәле авылы № 109

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 елдан № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 11 нче статьясы, 22 нче ноябрь 2013 нче ел, № 909 «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» (2014 нче елның 14 нче гыйнварындагы 3 нче, 2015 нче елның 12 нче февралендәге 85 нче, 2016 нчы елның 3 нче октябрендәге 706 нчы, 2018 нче елның 9 нче ноябрендәге 984 нче үзгәрешләре белән ) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү буенча уртак инициативаны күрсәтергә:

«2020 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

- Иске Чүпрәленең Көньяк, Тынычлык, Татарстан, Болын, завод, Дуслык, Ш. Мөдәрис, бертуган Рәкыйповлар, Семенов, яшьлек, Техник урамнарындагы юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Чүпрәле авылының Мәктәп урамында җәяүлеләр күперен ремонтлау;

- Иске Чүпрәле авылында зиратларны карап тоту;

-Яңа Чүпрәленең Совет, Яшьләр, Заречная -1 урамнарындагы юл-урам челтәрләрен ремонтлау;

-Яңа Чүпрәле авылында зиратларны карап тоту;

Иске Элмәле авылы Колхоз урамы буенча урнашкан юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Элмәледә су белән тәэмин итүне проектлаштыру;
- Иске Элмәледә зиратны карап тоту;
- карт агачларны кисү;
- урам утларын ремонтлау

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталының Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе : С.Х. Сирукова